СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**Иске Чүриле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 16 » июль 2021 ел** **№ 24**

**Иске Чүриле авыл җирлеге 2015 елның 03.11.2015 7.1 номерлы карары белән расланган Иске Чүриле авыл җирлеге Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү шартлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2021елның 30 апрелендәге 109-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. « Иске Чүриле авыл җирлеге Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Иске Чүриле авыл җирлеге Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 03.11.2015 7.1 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Иске Чүриле авыл җирлеге Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү белән бәйле чыгымнарны каплау тәртибен һәм күләмнәрен билгели.».

Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре (алга таба - Хезмәткәрләр) дип муниципаль хезмәткәрләр, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазифаи затлары, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте вазифалары булмаган вазифалар биләүче хезмәткәрләр, шулай ук Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү һәм аларга хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче затлар аңлашыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Чүриле авыл
җирлеге башлыгы | Р.Т.Һидиятуллин